**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие – Йолдызлык» республика фестивале хәрәкәтенә ярдәм чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-682 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2015 елның 17 мартындагы ПУ-290 номерлы, 2015 елның 16 октябрендәге ПУ-992 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-508 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 27 августындагы ПУ-499 номерлы, 2020 елның 6 мартындагы ПУ-154 номерлы, 2021 елның 21 маендагы ПУ-399 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 20 маендагы 326 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен бер тапкыр бирелә торган еллык махсус дәүләт стипендияләрен гамәлгә куярга.

40 стипендия түләнә, дип билгеләргә, шул исәптән:

унбиш стипендия – һәркайсы унбиш мең сум күләмендә;

бер стипендия – егерме мең сум күләмендә;

биш стипендия – һәркайсы утыз мең сум күләмендә;

биш стипендия – һәркайсы утыз биш мең сум күләмендә;

тугыз стипендия – һәркайсы кырык мең сум күләмендә;

өч стипендия – һәркайсы кырык биш мең сум күләмендә;

«Вокал-соло» номинациясендә гран-при – бер стипендия җитмеш мең сум күләмендә;

«Хореография» номинациясендә гран-при – бер стипендия сиксән мең сум күләмендә.»;

б) «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Совет составында (алга таба – Совет):

Совет составыннан А.В. Хохоринны чыгарырга;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Б. Зариповның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы»;

Н.М. Һашимованың – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фонды башкарма директоры».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә. Әлеге Указның 1 пункты «а» пунктчасының гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 946